ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР КАРАР

29.11.2023 ел № 1

2024 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Ижевка авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан 50% ка киметеп 500 сум күләмендә кертергә, СВОда катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә :

1. Урам яктырткычларын сатып алу һәм ремонтлау;
2. Һәйкәлнең һәм скверның административ бина янындагы территориясен төзекләндерү
3. Ижевка авылына керү урынында стела сатып алу һәм урнаштыру
4. Үлән чабу (ягулык-майлау материаллары һәм хезмәт хакы)
5. Триммер сатып алу - 2 данә
6. Яшьләр тыкрыгы һәм Урман урамы буенча вак таш сатып алу, китерү , тигезләү
7. Трактор өчен прицеп ( самосвал) сатып алу
8. Тракторга техник хезмәт күрсәтү һәм механизаторга хезмәт хакы түләү
9. Региональ юлга чыгучы җирле юл төзү

2. Ижевка авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Ижевка авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ижевка авыл җирлеге җитәкчесе
вазифаларын Р.Т.Масагутова